ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2022 п.г.т.Алексеевское № 50

**2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 маддәләре, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бердәм торак комиссиясен төзү турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 470 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2022 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы бусагасы:

1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 193346 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 1 518 804 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 1 952 748 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 603 664 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 3 254 580 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 3 905 496 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен - 4 556 412 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 30 263 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 19 258 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 13 797 сум;

2. Бердәм торак комиссиясенә аларны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында һәр гаилә әгъзасының яисә ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларына таянырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2022 елның 21 февралендәге
50 номерлы карарына
кушымта

**2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү исәп-хисабы**

1. Алексеевск муниципаль районының уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе формула буенча билгеләнә:

РПС = (Цп.р.+Цв.р.)/ni,   кайда:

РПС – торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече.

«Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакын билгеләү Методикасын раслау турында» 2021 елның 18 августындагы 584/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән расланган Методика кулланыла.

Цп.р. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясе. «ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» НОның 45300 сум күләмендә уртача тәкъдиме кулланылган.

Цв.р. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында икенчел базарда торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясе 1 кв. метрга 27024 сум тәшкил итә. Мәгълүматлар «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге»нең 2022 елның 02 февралендәге 28 номерлы хаты нигезендә кулланылган.

ni - торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясенең күрсәткечләрен исәпләгәндә кулланылган күләм күрсәткече (Цп.р., Цв.р.).

РПС = (45300+27024)/2 = 36 162 сум

2. СЖ = НП х РС х РПС, кайда:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күләме;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РПС - торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап

бәясе-36 162 сум.

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

СЖ = 36162 x 33 = 1 193346 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 42 = 1 518804 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 18 x 3 = 1 952748 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 18 x 4 = 2 603664 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 18 x 5 = 3 254580 сум

е) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 18 x 6 = 3 905496 сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 36162 x 18 x 7 = 4 556412 сум.

3. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

ПД =0,7 x СЖ x ПС/(1-(1 + ПС)$^{-КП}$)/(0,3 x РС), кайда:

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (беренче кертем шарты белән «Татарстан Республикасының ипотека торак кредитлавы агентлыгы» АҖ мәгълүматы буенча еллык 10,2 %, ягъни аена 10,2/100/12 %, беренче кертем 20 % булса;

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (кредит бирү срогы 15 ел яисә 180 ай) «Татарстан Республикасы ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматы нигезендә;

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте,

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 x 1 193346 x 10,2/100/12/ (1- (1 + 10,2/100/12)$^{-180}$) /(0,3 x 1) = 30263 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

ПД = 0,7 x 1 518804 x 10,2/100/12/ (1-(1 + 10,2/100/12)$^{-180}$) /(0,3 x 2)= 19258 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешенең гаиләсенә;

ПД = 0,7 x 1 952748 x 10,2/100/12/ (1-(1 + 10,2/100/12)$^{-180}$) /(0,3 x 3)= 16507 сум